**Республика Татарстан**
**Руководитель Исполнительного комитета Нижнебишевского сельского поселения Заинского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Түбән Биш авыл җирлегенең башкарма комитеты җитәкчесе**

Ул. Центральная, д. 46, с. Нижнее Бишево, Заинский район, 423514

Центральная урамы, 46 нче йорт, Түбән Биш авылы, Зәй районы, 423514

Телефон, факс 68-4-47. Электронный адрес: Nbsh.Zai@tatar.ru, сайт: www.nigneebishevo.ucoz.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**«27» март 2018 ел** **№ 3**

**«2015-2018 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерүнең муниципаль программасы турында» 2015 елның 10 июнендәге 10 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге Уставына таянып,

**карар бирәм:**

1. «2015-2018 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерүнең муниципаль программасы турында» 2015 елның 10 июнендәге 10 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-Россия Федерациясенең дәүләт программаларын (ярдәмче программаларын), Россия Федерациясе субъектларының дәүләт программаларын (ярдәмче программаларын), муниципаль программаларны (ярдәмче программаларны) тормышка ашыру максатларында кабул ителә торган Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Россия

Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән шартларга туры килгән күрсәтелгән программаларда (ярдәмче программаларда) катнашуга кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бертигез керү мөмкинлеге;» ;

1.2. түбәндәге эчтәлекле 8.1 пунктны өстәргә:

«8.1. **Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын төзүче оешмаларга мөлкәти ярдәм күрсәтү**

Ярдәм муниципаль мөлкәткә, шул исәптән җир кишәрлекләрен, биналарны, төзелешләрне, корылмаларны, торак булмаган биналарны, җиһазларны, машиналарны, механизмнарны, җайланмаларны, транспорт чараларын, инвентарьларны, инструментларны, түләүле нигездә, түләүсез нигездә яисә ташламалы шартларда Россия Федерациясе дәүләт программалары (ярдәмче программалары), Россия Федерациясе субъектларының дәүләт программалары (ярдәмче программалары) нигезендә дәүләт программалары (ярдәмче программалары), муниципаль программалар (ярдәмче программалар) нигезендә тапшыру рәвешендә гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән мөлкәт максатчан билгеләнеше буенча файдаланылырга тиеш.».

2. Әлеге карарны Түбән Биш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Д.В.Насертдинов**